*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) урманның
   ә) урманны
   б) урманнан
   в) урман

2. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Куян куып йөрү***
   а) бик тиз йөгерү
   ә) файдасыз эш артыннан йөрү
   б) файдалы эш башкару
   в) ялагайлану

3. Кыскартылма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) иттарткыч
   ә) суыткыч
   б) бишбармак
   в) драмтүгәрәк

4. Билгесезлек алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) минеке
   ә) ниндидер
   б) кайсы
   в) берни

5. Ияртүче теркәгечне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) һәм
   ә) белән
   б) чөнки
   в) юк

6. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Кешенең сүзе эшеннән аерылмасын.* (Мәкаль).

а) кешенең
ә) сүзе
б) эшеннән
в) аерылмасын

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Ун адәм салган күперне **бер** адәм бозар*. (Мәкаль).
а) ия
ә) күләм хәле
б) тәмамлык
в) аергыч

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Эше барның көче бар*. (Мәкаль).
а) иярчен ия җөмлә
ә) иярчен хәбәр җөмлә
б) иярчен аергыч җөмлә
в) иярчен тәмамлык җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Сүздәге морфемаларны һәрвакыт бертөрле язу һәм сөйләмдәге аваз үзгәрешен күрсәтеп тормау ___________ принцип була. Язылышлары бердәй, әмма әйтелешләрендә аерма булган сүзләр ___________ дип атала. Ялгызлык исемнәр һәрвакыт _____________ хәрефтән языла._____________ сыйфатлар дәрәҗә белән төрләнмиләр. Инкяр җөмлә *юк* һәм ___________ сүзләре белән белдерелә.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

*Лось обитает в сибирской тайге, в лесах под Москвой. Лось передвигается по болоту с необыкновенной лёгкостью. Ему помогают длинные ноги с большими копытами. Он разыскивает на дне болот нежные корешки водных растений. Лось превосходно плавает и легко преодолевает большие реки.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.

*Белем алу суганнан ачы, азагы балдан татлы*. (Мәкаль)

2.1. Тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзне языгыз. **(1 балл)**
2.2. Яңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзне языгыз. **(1 балл)**
2.3. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзләрне языгыз. **(1 балл)**
2.4. Ясалма нигезле сүзләрне языгыз. **(2 балл)**
2.5. Антоним сүзләрне парлап языгыз. **(1 балл)**

2.6. *Суганнан*, *балдан* нинди җөмлә кисәкләре? **(2 балл)**

2.7. Җөмләнең баш кисәкләрен, компонент чикләрен билгеләгез; җөмләнең билгеләмәсен языгыз. **(5 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 10 җөмлә языгыз. **(16 балл)**